ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «дифференциацияләнгән» сүзен төшереп калдырырга;

2) 1 статьяда:

а) 1 өлештә «346$^{20}$ статьясы» сүзләрен «346$^{20}$ статьясының 2 пункты» сүзләренә алмаштырырга, «дифференциацияләнгән» сүзен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 4 пункт өстәргә:

«4) югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резидентлары булып торучы салым түләүчеләр өчен, тиешле хисап (салым) чоры өчен керемнең кимендә 90 процентын Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының 62 «Компьютер программаларын эзерләү, шушы өлкәдә консультация хезмәтләре күрсәтү һәм башка хезмәт күрсәтүләр» һәм 63 «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә эшчәнлек» кодларына туры килә торган икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан алынган керем тәшкил иткән очракта.

Әлеге Закон максатларында югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резидентлары дигәндә инновация эшчәнлеге турында килешү төзегән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резидентлары реестрына кертелгән хуҗалык җәмгыятьләре һәм шәхси эшмәкәрләр аңлашыла.»;

3) 1[1] статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**1[1] статья**

1. Россия Федерациясе Салым кодексының $346^{20}$ статьясының 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы һәм керемнәрне салым салу объекты сыйфатында билгеләгән салым түләүчеләр өчен салым ставкасын әлеге статьяның 2 өлешендә каралган күләмдә билгеләргә.

2. Түбәндәгеләргә салым ставкасын 1 процент күләмендә билгеләргә:

1) тиешле хисап (салым) чоры өчен керемнең кимендә 90 процентын Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының 62 «Компьютер программаларын әзерләү, шушы өлкәдә консультация хезмәтләре күрсәтү һәм башка хезмәт күрсәтүләр» һәм 63 «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә эшчәнлек» кодларына туры килә торган икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан алынган керем тәшкил иткән очракта, федераль башкарма хакимиятнең Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыручы органы мәгълүматы буенча халык саны 7 мең кешегә кадәр җиткән шәһәрләрдә тору урыннары (яшәү урыннары) булган салым түләүчеләр өчен;

2) тиешле хисап (салым) чоры өчен керемнең кимендә 90 процентын Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының 62 «Компьютер программаларын әзерләү, шушы өлкәдә консультация хезмәтләре күрсәтү һәм башка хезмәт күрсәтүләр» һәм 63 «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә эшчәнлек» кодларына туры килә торган икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан алынган керем тәшкил иткән очракта, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резидентлары булып торучы салым түләүчеләр өчен.»;

4) 2 статьяда:

а) 3 пунктта «1[1] статьясының» сүзләрен «1[1] статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктын» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлектәге 4 пункт өстәргә:

«4) 2024 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 1 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктын һәм 1[1] статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктын.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 27 ноябрь
№ 82-ТРЗ